# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
# ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
# НОВОТРОИЦК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

## КАРАР

«11» июнь 2025 ел № 61/2

Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Новотроицк авыл җирлеге Советының 2021 елның 15 июнендәге 12/1 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Новотроицк авыл җирлегендә гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

2024 елның 28 декабрендәге 547-ФЗ номерлы Федераль закон, Тукай муниципаль районы Теләнче-Тамак авыл җирлеге уставы нигезендә Совет

**КАРАР БИРДЕ:**

1. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Новотроицк авыл җирлеге Советының 2021 елның 15 июнендәге 12/1 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Новотроицк авыл җирлегендә гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 5 бүлеккә түбәндәге эчтәлектәге 5.3 пунктын өстәргә:

«Россия Федерациясенең оператив-эзләү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы органнарга яки Россия Федерациясенең иминлеген тәэмин итүне гамәлгә ашыручы органнарга, күрсәтелгән органнарның вазыйфаи затларына мөрәҗәгатьләренә бәйле рәвештә гражданнарның иминлеген тәэмин итү максатында, Эчке эшләр өлкәсендә федераль башкарма хакимият органының, иминлекне тәэмин итү өлкәсендә федераль башкарма хакимият органының, Тышкы разведка өлкәсендә федераль башкарма хакимият органының, дәүләт саклавы өлкәсендә федераль башкарма хакимият органының норматив хокукый актлары белән мөрәҗәгатьләрне электрон документ формасында җибәрүнең һәм мөрәҗәгатьләргә җавапларны, хәбәрнамәләрне җибәрүнең махсус тәртибе билгеләнергә мөмкин.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм интернет челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Тукай муниципаль районының мәгълүмат сайтында (https://tukay.tatarstan.ru/) урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә.

4. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Новотроицк авыл җирлеге Башлыгы,
Совет Рәисе Д.М. Габделхаева